ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

# Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Өчкүл авыл җирлегенең Өчкүл торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

2024 елның 31 октябрендәге 2 номерлы

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Өчкүл авыл җирлегенең Өчкүл торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

Карар кылдым:

1.2025 елда Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Өчкүл авыл җирлегенең Өчкүл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә::

«1) Өчкүл торак пунктында урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (энергияне саклый торган яктырткычлар һәм урамнарны яктырту лампаларын, электр товарларын сатып алу, урнаштыру, урамнарны агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү (эшләр өчен түләү) һәм килешү буенча хезмәт күрсәтүләр));

2) Өчкүл торак пункты территориясен төзекләндерү (юлларны кардан чистарту, территорияне чабу (МТЗ – 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу килешү буенча эшләр өчен түләү) 1 шт күләмендә триммер сатып алу);

3) Өчкүл торак пунктында каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү ( рөхсәтсез чүплекләрне бетерү ( эшләр һәм транспорт хезмәтләре өчен килешү буенча түләү))»

3. Өчкүл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә халыкка җиткерергә, Спас муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http:// spasskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru)

Спас муниципаль районы
Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Өчкүл авыл җирлеге башлыгы Н.В. Емелюшина

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТРЕХОЗЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТРЕХОЗЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1637005571 ОГРН 1061677000395